КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 апрель г.Казань № 355

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 393 нче; 2018 ел, 3 август, 631 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1152 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1227 нче; 2021 ел, 19 июль, 587 нче; 2021 ел, 31 август, 791 нче, 2021 ел, 12 ноябрь, 1065 нче, 2022 ел, 18 гыйнвар,

22 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә җир кишәрлекләре бирелмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру мөмкин булган объектлар төрләре исемлеген раслау турында» 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы карары белән расланган Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә җир кишәрлекләре бирелмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру мөмкин булган объектлар төрләре исемлегенең (алга таба - Исемлек) 25 пунктында күрсәтелгән объектларны урнаштыру аларны урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган велосипедлар, роликлар, самокатолар һәм башка спорт инвентарьлары прокат пунктларын, шулай ук Татарстан Республикасында җирлекләрнең, шәһәр округларының җирле үзидарә органы тарафыннан раслана торган велопаркларны урнаштыру схемасы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасы өстәргә:

«з) объектны 25 пунктта күрсәтелгән исемлектән урнаштыру планлаштырыла торган урыны велосипедлар, роликлар, самокатолар һәм урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт таләп ителмәгән башка спорт инвентарьлары прокат пунктларын, шулай ук әлеге Тәртипнең 3 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән велопарклар урнаштыру схемасы каралмаган.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин